| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.10.2018 г.Казань № 950

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 23 ноябрендә 4990 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга

күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 950 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Халыкның мәшгульлек үзәкләре, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен эшли. Эш сәгатьләре Халыкның мәшгульлек үзәгенең эчке тәртип кагыйдәләренә туры китереп билгеләнде.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, халыкның мәшгульлек үзәгенең эш сәгатьләрендә.

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәгенең урнашкан урыны һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Халыкның мәшгульлек үзәге бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) (http://www.mtsz.tatarstan.ru), халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренә мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) халыкның мәшгульлек үзәгенә, Министрлыкка (mtsz@tatar.ru) язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст.);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү турында 1032-1 номерлы закон) (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1991, № 18, 566 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 к.), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын

камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны теркәүгә алу, эшсез гражданнарны теркәүгә алу тәртибе һәм туры килә торган эш эзләүгә карата таләпләр турында» 2012 елның 07 сентябрендәге 891 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 17.09.2012, № 38, 5103 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Персональ мәгълүматларның мәгълүмат системаларында эшкәрткәндә персональ мәгълүматларны яклауга карата таләпләр раслау турында» 2012 елның 1 ноябрендәге 1119 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 45, 6257 ст.);

«Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны финанслау тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2005 елның 29 июлендәге 485 номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны финанслау тәртибе турында нигезләмә (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2005, № 39, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучыларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы (Российская газета, 2011, 2 февраль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек хезмәте органнары һәм медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы (алга таба – 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 5);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (алга таба – 486н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының

шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерыгы (алга таба – 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель, «Российская газета», 28.02.2014 № 48);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашканда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 7 мартындагы 92н номерлы боерыгы белән расланган Мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашканда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (алга таба – 92н номерлы Стандарт), (Российская газета, 2013, 28 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 05.09.2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына һәм эшсез гражданнарга күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 июнендәге 515 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күчеп киткәндә эшсез

гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына һәм эшсез гражданнарга күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибе (алга таба – 515 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 47, 1605 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

– дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

– КФҮ читтән торып эшләү урыны – КФҮнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы)»;

– яңа яшәү урыны – гражданин даими рәвештә яки башлыча башка җирлектә милекче буларак найм (поднайм) шартнамәсе, махсуслаштырылган торак урынның найм шартнамәсе буенча яки Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән нигезләрдә яши торган һәм ул аларда яшәү урыны буенча теркәлгән торак йорт, фатир, бүлмә, махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны яки бүтән төрле торак урын;

– дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба - шикаять) - мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, КФҮ, дәүләт хезмәте күрсәтү органның вазыйфаи заты, КФҮ хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

– техник хата  дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

дигәндә (алга таба гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1,2 пункты). Гариза формасы 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерык белән расланган.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «Халык мәшгульлеге турында законның 7.1-1 ст. 1 өл. 8 п.» сүзләрен «Халык мәшгульлеге турында законның 7.1-1 ст. 1 п. 8 п.п.» сүзләре белән алмаштырырга;

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.»

2.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган срогы 30 минуттан артып китәргә тиеш түгел, күченү турында шартнамә (күченеп урнашу турында шартнамә) төзү өчен, шулай ук эшсез гражданинга (эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына) финанс ярдәме күләмен билгеләү һәм аны банкта яки башка төрле кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерү өчен кирәкле вакыттан тыш.<br>Инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданнарга дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, үз инициативасы белән инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын (алга таба – хосусый программа) яки медик-социаль экспертиза (алга таба – МСЭ) буенча федераль учреждениедән билгеләнгән тәртиптә бирелгән хосусый программа өземтәсе (инвалидлар категориясенә караучы гражданнар өчен) тапшырылмаган очракта, һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаганда, гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне тәшкил итә.<br>Эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләнгәндә, финанс чаралары Халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көннән башлап календарь | 92н номерлы Стандартның 19 п.<br><br>2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыкка 3 нче кушымтаның 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | көннәрендә исәпләнә торган 7 көнлек срокта 515 номерлы Тәртиптә һәм төзелгән шартнамәдә каралган шартлар нигезендә эшсез гражданин тарафыннан күрсәтелгән шәхси счетка (исәп-хисап счетына) күчерелә.<br>Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Эшсез гражданинның мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килешенгән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Эшсез гражданин КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында төзелгән хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган. | 515 номерлы Тәртипнең 3.3 п.<br><br>92н номерлы Стандартның 8 п.<br><br>92н номерлы стандартның 9 п.»; |

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан | 1. 2015 елның 26 февралендәге 125 н номерлы боерыкка 37 нче кушымтага туры китерелгән формада халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт | 92н номерлы Стандартның 5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме) һәм дәүләт хезмәте алучының 2015 елның 26 февралендәге 125 н номерлы боерыкка 38 нче кушымтага туры китерелгән формада халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме белән ризалашуы.<br>2. Эшсез гражданин мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны) күрсәтә.<br>3. Гаилә әгъзалары булган эшсез гражданин эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм буенча дәүләт хезмәтен алу өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>үзенең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, – чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, – гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләрен; | 92н номерлы Стандартның 14 п.<br>92н номерлы Стандартның 15 п.<br><br>92н номерлы Стандартның 15 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | эшсез гражданинның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):<br>аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;<br>эшсез гражданинның персональ белешмәләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырганда алар исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле булуын.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана.<br>4. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан финанс ярдәмен билгеләү һәм халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә вакытлыча эшкә урнашу өчен күченгәндә (яңа яшәү урынына күченеп урнашканда) эшсез гражданинга күчерү турында карарны кабул итү өчен эшсез гражданин 515 номерлы Тәртипкә 1-4 нче кушымталарга туры китерелгән форма буенча гариза тапшыра, түбәндәге документларны теркәп:<br>вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә:<br>эшкә алучы белән төзелгән, билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт шартнамәсенең күчермәсен;<br>Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (төп нөсхәсе тапшырылмаган очракта), эшкә алу (хезмәт шартнамәсенең яки күченү турында шартнамә срогы узуга бәйле рәвештә эштән китү) турында язуы белән;<br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктларында каралган чыгымнар | 515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 п.<br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.6 п.<br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.7 п. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | турындагы белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең әлеге пунктларында каралган чыгымнарны компенсацияләү очрагында);<br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 пункты нигезендә элегрәк өлешчә компенсацияләү очрагында);<br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары нигезендә элегрәк компенсация гамәлгә ашырылмаган очракта);<br>банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен;<br>эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашканда:<br>эшкә алучы белән төзелгән, Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт шартнамәсенең күчермәсен;<br>Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен (төп нөсхәсе тапшырылмаган очракта), эшкә алу турында язуы белән;<br>эшсез гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының күченеп урнашу буенча транспорт чыгымнары, яңа яшәү урынына барган вакытта тәүлеклек чыгымнары һәм элеккеге яшәү урыныннан яңа яшәү урынына йорт мөлкәтен алып бару бәясен түләү чыгымнары (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, исәп-хисап-фактуралары, квитанцияләр, касса чеклары һ.б.) турында белешмәләрне | 515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 п.<br><br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.6 п.<br><br>515 номерлы Тәртипнең 2.1.7 п.<br><br>515 номерлы Тәртипнең 2.2.5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | раслаучы документларның төп нөсхәләре;<br>эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсен;<br>эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләрен;<br>гаилә әгъзаларының персональ белешмәләрен тапшырганда эшсез гражданинның гаилә әгъзалары исеменнән яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш итүгә вәкаләтле булуын раслаучы документны;<br>банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен.<br>Гариза эшсез гражданинның шәхси яки 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре, паспорт күчермәсен яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен дә кертеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучының вәкиле өстәмә рәвештә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен белдерүгә үзенең вәкаләтле булуын раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза кәгазен эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар эшсез гражданин тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә эшсез гражданин исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан); | 92н номерлы стандартның 5 п.»; |

| | | |
|---|---|---|
| | почта аша.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук эшсез гражданин тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана. | |

2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>– эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);[1]<br>– гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);[2]<br>– гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешмаларда);<br>– хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:<br>эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);<br>организмының бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр. | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 ст.»; |

| | | |
|---|---|---|
| үзидарә органы яисә оешма | Аталган белешмәләр аларны МСЭ буенча федераль учреждение мөстәкыйль җибәрмәгән очракта, 486 н номерлы боерыкка 1 нче кушымтаның 14 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә соратыла.<br>Эшсез гражданин шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Эшсез гражданин тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданиннан түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнарыннан, Россия Федерациясе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә. | |

таблицаның 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 астөшермә текстын өстәргә:

«[2] Алга таба – гаилә кору турында таныклык»;

2.15 пунктта «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында «880 номерлы ТР МК карарының 2.4 п.» сүзләрен «ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.4.2.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2.1. Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерык белән расланган (37 нче кушымта) форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны килгән көнендә кабул итә һәм терки. Зарурлык булганда эшсез гражданинга гариза тутырырга ярдәм итә.

Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә почтадан, факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон формада, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы Порталыннан файдаланып килгәндә яки гариза КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән килүче эш көненнән соңга калмыйча гражданин белән шәхси кабул итү датасын, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, «Интернет» челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шәхсән кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында каралган документ булуын тикшерә;

дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплекска дәүләт хезмәтен алучы турындагы белешмәләрне эзләтү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә тиешле исәпкә алу документлары бланкларын таба;

эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәгендә эшсез гражданин сыйфатында тору-тормавын, эшсез гражданинныж инвалидлар категориясенә карау-карамавын (халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме һәм эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме белән ризалашуы булган очраклардан тыш) билгели;

халыкның мәшгульлек үзәгенең гамәлдәге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен ала (булган очракта).

Инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданин тарафыннан үз инициативасы белән МСЭ буенча федераль учреждениедән бирелгән хосусый программа тапшырылмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 ел, 16 ноябрь, 872н номерлы боерыгы нигезендә, халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында организмының бозылган функцияләрен

һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның хезмәт һәм һөнәри эшчәнлеге буенча киңәш ителә торган төрләрне сайлау өчен электрон формада белешмәләр ала.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында һәм 2.6 пунктының бишенче абзацында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтага туры китерегән язмача формада дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән кул куйдыртып таныштыра.

Әгәр эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән кул куйдыртып таныштырылмаса, аның адресына дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында язмача хәбәрләмә җибәрелә.

Әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән баш тарту нигезләре булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләүне дәвам иттерә.

Процедураларны башкару срогы:

әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап 10 минуттан артмаган чорда гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса, яки әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булган очракта;

әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданин үз инициативасы белән хосусый программаны тапшырмаган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаса.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан дәүләт хезмәте алуга кабул ителгән гариза, белешмәләр бирү турында гарызнамә, электрон формада алынган белешмәләр, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.»;

3.4.2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим ясау (алга таба - халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме).

Эшсез гражданнарны теркәүгә алуны алып баручы халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин кулай эш сайлау өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килгәндә:

әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында каралган документ булуын тикшерә;

дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплекска дәүләт хезмәтен алучы турындагы белешмәләрне эзләтү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә тиешле исәпкә алу документлары бланкларын таба;

халыкның мәшгульлек үзәгенең гамәлдәге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен ала (булган очракта);

дәүләт хезмәтен тәкъдим итә һәм гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы белән расланган форма буенча рәсмиләштерү юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булуын (риза булмавын) рәсмиләштерә.

Халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында организмының бозылган функцияләрен һәм чикләнгән яшәешен исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен электрон формада белешмәләр ала.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында һәм 2.6 пунктының бишенче абзацында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтага туры китерегән язмача формада дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән кул куйдыртып таныштыра.

Әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән баш тарту нигезләре булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләүне дәвам иттерә.

Процедураларны башкару срогы:

әлеге пунктта каралган процедуралар халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән эшсез гражданин кулай эшне сайлап алу өчен әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында каралган документны тапшырган вакыттан башлап 10 минуттан артмаган чорда гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса, яки әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булган очракта;

әлеге пунктта каралган процедуралар, инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданин хосусый программаны үз инициативасы белән тапшырмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән эшсез гражданин кулай эшне сайлап алу өчен әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында

каралган документны тапшырган вакыттан башлап 7 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим белән ризалашуны (риза булмауны) күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсмиләштерелгән тәкъдим, белешмәләр бирү турында гарызнамә, электрон формада алынган белешмәләр, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.»;

3.4 пунктта 3.4.6 пунктчаның дүртенче абзацында «пунктларда каралган» сүзләрен «пунктчаларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта 3.4.9 пунктчаның бишенче абзацында «1.5 пунктчада» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның 3.4.10 пунктчасында:

икенче абзацта «1.5, 1.5.1.1-1.5.1.4 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләре белән алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1.5.1.1-1.5.1.4 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче һәм тугызынчы абзацларда «1.5.1.1-1.5.1.4 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның 3.4.13 пунктчасында:

икенче абзацта «пунктларда каралган» сүзләрен «пунктчаларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «пунктларда каралган» сүзләрен «пунктчаларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2.1. Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерык белән расланган (37 нче кушымта) форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны килгән көнендә кабул итә һәм терки. Зарурлык булганда эшсез гражданинга гариза тутырырга ярдәм итә.

Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә почтадан, факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон формада, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы Порталыннан файдаланып килгәндә яки гариза КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән килүче эш көненнән соңга калмыйча гражданин белән шәхси кабул итү датасын, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, «Интернет» челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шәхсән кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындаг 2, 3 пунктчаларда каралган документлар булуын тикшерә;

дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплекска дәүләт хезмәтен алучы турындагы белешмәләрне эзләтү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә тиешле исәпкә алу документлары бланкларын таба;

эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәгендә эшсез гражданин сыйфатында тору-тормавын, эшсез гражданинның инвалидлар категориясенә карау-карамавын (халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме һәм эшсез гражданинның халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме белән ризалашуы булган очраклардан тыш) билгели;

халыкның мәшгульлек үзәгенең гамәлдәге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен ала (булган очракта);

тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, 3.5.3 пунктчада каралган процедураны башкара.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2, 3 пунктчаларында һәм 2.6 пунктында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтага туры китерегән язмача формада дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән кул куйдыртып таныштыра.

Әгәр эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән кул куйдыртып таныштырылмаса, аның адресына дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында язмача хәбәрләмә җибәрелә.

Әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән баш тарту нигезләре булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләүне дәвам иттерә.

Процедураларны башкару срогы:

әлеге пунктта каралган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап 10 минуттан артмаган чорда гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса, яки әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булган очракта;

әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданин үз инициативасы белән хосусый программаны тапшырмаган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаса.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан дәүләт хезмәте алуга кабул ителгән гариза, белешмәләр бирү турында гарызнамә, электрон формада алынган белешмәләр, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.»;

3.5.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан эшсез гражданинга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашканда ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим ясау (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме).

Эшсез гражданнарны теркәүгә алуны алып баручы халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданин кулай эш сайлау өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килгәндә:

әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындаг 2, 3 пунктчаларда каралган документлар булуын тикшерә;

дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплекска дәүләт хезмәтен алучы турындагы белешмәләрне эзләтү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә тиешле исәпкә алу документлары бланкларын таба;

халыкның мәшгульлек үзәгенең гамәлдәге архивыннан эшсез гражданинның шәхси эшен ала (булган очракта);

дәүләт хезмәтен тәкъдим итә һәм гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы белән расланган форма буенча (38 нче кушымта) рәсмиләштерү юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән риза булуын (риза булмавын) рәсмиләштерә;

тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, 3.5.3 пунктчада каралган процедураны башкара.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2, 3 пунктчаларында һәм 2.6 пунктында каралган документлар (белешмәләр) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эшсез гражданинга баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтага туры китерегән язмача формада дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән кул куйдыртып таныштыра.

Әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән баш тарту нигезләре булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламент нигезендә эшсез гражданин белән эшләүне дәвам иттерә.

Процедураларны башкару срогы:

әлеге пунктта каралган процедуралар халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән эшсез гражданин кулай эшне сайлап алу өчен әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2, 3 пунктчаларында каралган документларны тапшырган вакыттан башлап 10 минуттан артмаган чорда гамәлгә ашырыла, әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә карамаса, яки әгәр эшсез гражданин инвалидлар категориясенә караса һәм үз инициативасы белән хосусый программа тапшырылган булса яки халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булган очракта;

әлеге пунктта каралган процедуралар, инвалидлар категориясенә караучы эшсез гражданин хосусый программаны үз инициативасы белән тапшырмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә хосусый программа өземтәсе булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән эшсез гражданин кулай эшне сайлап алу өчен әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 2, 3 пунктчаларында каралган документларны тапшырган вакыттан башлап 7 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим белән ризалашуны (риза булмауны) күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсмиләштерелгән тәкъдим, белешмәләр бирү турында гарызнамә, электрон формада алынган белешмәләр, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.»;

3.5 пунктның 3.5.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3.1. Тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органнарына тиешле гарызнамәне (гарызнамәләрне) җибәрә.

- эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында (ГХАТ органнарында);

- гаиләне дәүләт теркәвенә алу турында (ГХАТ органнарында);

- организмының бозылган функцияләрен һәм чикләнгән яшәешен исәпкә алып, иналидка киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләре турында (хосусый программадан өземтә).

Үтәү вакыты: процедура гариза яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.»;

3.5 пунктның 3.5.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән гарызнамәләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) бирәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) белешмәләрнең булмавы турында хәбәрләмә җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган белешмәләр.»;

3.5 пунктта 3.5.7 пунктчаның дүртенче абзацында «пунктларда каралган» сүзләрен «пунктчаларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның 3.5.10 пунктчасында:

икенче, дүртенче абзацларда «1.5 пунктчада» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның 3.5.11 пунктчасында:

икенче абзацта «1.5, 1.5.2.1-1.5.2.6 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләре белән алмаштырырга;

өченче, дүртенче абзацларда «1.5.2.1-1.5.2.6 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы, җиденче абзацларда «1.5.2.1-1.5.2.6 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «1.5.2.1-1.5.2.6 пунктчаларда» сүзләрен «4 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы һәм унынчы абзацларда «күчереп урнаштырганда» сүзләреннән алда «яңа яшәү урынына» сүзләрен өстәргә;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук андагы дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшерүдә тотучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү

өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче учреждение, дәүләт хезмәте күрсәтүче учреждениенең белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatarstan.ru), КФҮ рәсми сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/), халыкның мәшгульлек үзәкләренең рәсми сайтларыннан җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт

хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең (учреждение белгеченең), КФҮ, КФҮ хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең (учреждение белгеченең), КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең яки дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең) дәүләт хезмәткәренең (белгеченең), КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи заты (белгече) яки дәүләт хезмәткәре, КФҮ, КФҮ хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен

алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар, учреждениеләр һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкның мәшгульлек үзәге аталышы | Телефоны | Урнашкан урынының адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (85551) 2-31-73 | 422230, Әгерҗе ш., Карл Маркс ур., 11а Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай ш., Төзүчеләр ур., 10 Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.п, Романов ур., 6 Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 61 Czn.Aktanysh@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск ш.т.п., Ленин ур., 87 Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8553) 32-34-99 | 423452, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас авылы, Шоссейная ур., 5 Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6в Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә ав., Совет ур., 63 Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56 Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.п., Совет ур., 16 Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85594) 4-17-60 | 423239, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 15 Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84374) 3-35-89 | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 159 Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84379) 2-24-28 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 21а Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84365) 2-16-17 | 422700, Биек Тау ав., Үзәк ур., 7 CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84375) 2-25-87 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й. Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85557) 7-58-58 | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 37б Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Яшел Үзән шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84371) 5-64-90 | 422550, Яшел Үзән ш., Татарстан ур., 1 Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84370) 2-12-60 | 422330, О.Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 й. Czn.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы районы буенча «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (84377) 2-14-67 | 422820, Кама Тамагы ш.т.п., Карл Маркс ур., 2 Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84364) 2-67-54 | 422110, Кукмара ш., Ворошилов ур., 44 Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84378) 2-48-12 | 422610, Лаеш ш., Чернышевский ур., 23 Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85595) 5-59-70 | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 Czn.Leninogorsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85549) 2-23-57 | 423650, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 Czn.Men@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә., Ленин ур., 80 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85556) 2-55-80 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8552) 52-42-68 | 423831, Яр Чаллы ш, Сөембикә пр., 47 Chelny.CZn@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8555) 42-40-79 | 423570, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20а Czn.nk@tatar.ru |
| Кама Аланы бүлеге «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8555) 33-98-61 | 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы ш.т.п., 2/01 Czn.nk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84348) 2-30-42 | 423190, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат ш., Р.С.Хәммәдиев ис.ур., 19 Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч ав., Совет ур., 20 й. CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.п., Ленин ур., 48 Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84362) 2-28-16 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.п., Закир Йосыпов ур., 7 й. SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман ав., Ленин ур., 26 Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84373) 2-63-29 | 422370, Тәтеш ш., Ирек мәйданы ур., 45 Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай районы буенча «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (8552) 52-96-97 | 423831, Яр Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче ав., Ленин ур., 73. Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән ав., Титов ур., 26 й. Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай ш., К.Маркс ур., 35 й. Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85593) 2-98-00 | 423950, Урыссу ш.т.п.,Пушкин ур.,105/1й. Czn.Yutazy@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 562-48-33 | 420034, Казан ш., Декабристлар ур., 81а Czn.g_Kazan@tatar.ru |
| Совет районы буенча «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (843) 273-85-03 | 420029, Казан ш., Журналистлар ур., 13а CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 537-86-00 | 420085, Казан ш., 1 нче Муром ур., 33а Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 277-40-09 | 420049, Казан ш., Качалов ур., 77 Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 554-77-36 | 420032, Казан ш., Слободская ур., 23 czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 564-58-72 | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46, czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 560-88-98 | 420044, Казан ш., Ибраһимов пр., 41, Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 224-86-83 | 420101, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., 22/7 CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа атылышы | Телефоны | электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | mtsz@tatar.ru |
| Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы | 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа атылышы | Телефоны | электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе башлыгы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru»; |

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә булышлык күрсәтү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы**

Шәхсән, почта аша, ш.и. КФҮ аша, электрон формада гариза һәм 2.5 пунктның 1. пунктчасы нигезендә документлар тапшыру

Мөрәҗәгать итүче (эшсез гражданин)

Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең дәүләт хезмәте турында тәкъдиме

Дәүләт хезмәтләрен алучылар регистрында эшсез гражданин турындагы белешмәләрне анализлау һәм 2.5 пунктның 2 пунктчасында билгеләнгән документны тикшерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән көнне - 2 минут)

Хезмәт күрсәтелми

Хезмәт күрсәтелә


2.9 пункт нигезләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү

Гаризаня яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдимен Дәүләт хезмәте алучылар регистрына тиешле белешмәләр кертү юлы белән теркәү

Халыкның мәшгульлек үзге, халыкның мәшгульлек үзәкләре һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында, инвалидның хезмәт һәм һөнәри эшчәнлеге буенча киңәш ителә торган төрләрне сайлау өчен электрон формада белешмәләр (хосусый программадан өземтә) ала, хосусый программа яки хосусый программа өземтәсе үз иницитивасы белән тапшырылмаган очракта) (гаризаны теркәгән датадан 7 эш көне эчендә)

Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, вакансияләр булуы (булмавы) турында, финанс ярдәме турында, аны күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында хәбәр итү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)

Эшсез гражданинга, Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, башка җирлектән эш вариантларын сайлау (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)


Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында туры килә торган
Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында туры килә торган вариантларның булмавы
Эшсез гражданинга эш вариантлары исемлеген тәкъдим итү
Буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында эш бирүчедән белешмәләр алынган очракта, эшсез гражданинны халыкның мәшгульлек үзәгенә килергә чакыру
Эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)
Эш бирүче белән вакансия булуын һәм эшсез гражданин кандидатурасын килештерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)
Кандидатура килештерелгәндә
Кандидатура килештерелмәгәндә
Эшкә юллама рәсмиләштерү һәм эшсез гражданинга тапшыру (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)
Эшсез гражданинга вариантлар сайлауны тәкъдим итү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)
Күченү турында шартнамә рәсмиләштерү һәм төзү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 15
Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан күченгәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү (2.5 пунктның 4 пунктчасында каралган гаризаны биргән көнне - 3 минут)
Бирү турында карар
Бирүдән баш тарту турында карар
2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документларны тикшерү һәм эшсез гражданинга финанс ярдәмен билгеләү турында яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү (документлар тапшырылган көнне - 3
Эшсез гражданинга кабул ителгән карарны җибәрү

Билгеләү турында карар

Билгеләүдән баш тарту турында карар

Эшсез гражданинга финанс ярдәмен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү һәм имзалау (документлар тапшырылган көнне - 2

Финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында боерык әзерләү һәм имзалау, эшсез гражданинга хәбәрләмә җибәрү (документлар тапшырылган көнне - 2 минут)

Эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү (халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көнне - 5 минут)

Дәүләт хезмәтен алучылар регистрына вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә эшсез гражданинга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү, финанс ярдәмен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр кертү яки дәлилле баш тарту"

3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

**Эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына башка җирлеккә күченеп урнашканда бул ярдәме күрсәтү буенча блок-схема**

Шәхсән, почта аша, ш.и. КФҮ аша, электрон формада гариза һәм 2.5 пунктның 1. пунктчасы нигезендә документлар тапшыру

Мөрәҗәгать итүче (эшсез гражданин)

Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең дәүләт хезмәте турында тәкъдиме


Дәүләт хезмәтләрен алучылар регистрында эшсез гражданин турындагы белешмәләрне анализлау, 2.5 пунктның 2, 3 пунктчаларында билгеләнгән документларны тикшерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән көнне - 2 минут)

Хезмәт бирелә

Хезмәт бирелми

2.9 пункт нигезләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү

Гаризаня яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдимен Дәүләт хезмәте алучылар регистрына тиешле белешмәләр кертү юлы


Халыкның мәшгульлек үзге, халыкның мәшгульлек үзәкләре һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында, инвалидның хезмәт һәм һөнәри эшчәнлеге буенча киңәш ителә торган төрләрне сайлау өчен электрон формада белешмәләр (хосусый программадан өземтә) ала, хосусый программа яки хосусый программа өземтәсе үз иницитивасы белән тапшырылмаган очракта) (гаризаны теркәгән датадан 7 эш көне эчендә)
Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, вакансияләр булуы (булмавы) турында, финанс ярдәме турында, аны күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында хәбәр итү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)
Эшсез гражданинга, Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, башка җирлектән эш вариантларын сайлау (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)
Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында туры килә торган
Дәүләт хезмәтен алучылар регистрында туры килә торган вариантларның булмавы
Эшсез гражданинга эш вариантлары исемлеген тәкъдим итү
Буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында эш бирүчедән белешмәләр алынган очракта, эшсез гражданинны халыкның мәшгульлек үзәгенә килергә чакыру
Эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)
Эш бирүче белән вакансия булуын һәм эшсез гражданин кандидатурасын килештерү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 3 минут)
Кандидатура килештерелгәндә
Кандидатура килештерелмәгәндә
Эшкә юллама рәсмиләштерү һәм эшсез гражданинга бирү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)
Эшсез гражданинга вариантлар сайлауны тәкъдим итү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 1 минут)

Күченеп урнашу турында шартнамә рәсмиләштерү һәм төзү (гариза биргән/халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим ясаган көнне - 15 минут)

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан күченеп урнашканда эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында яки эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына күченеп урнашканда финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү, кабул ителгән карар турында хәбәр итү (2.5 пунктның 4 пунктчасында каралган гаризаны биргән көнне - 3 минут)

Бирү турында карар

Бирүдән баш тарту турында карар

Элеккеге яшәү урыны буенча халыкның мәшгульлек үзәгендә гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында гаризаны һәм 2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документларны кабул итү, документлар булуын тикшерү (документларны тапшыру, аларның килү көнендә - 3 минут)

Яңа яшәү урыны буенча халыкның мәшгульлек үзәгендә гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында гаризаны һәм 2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документларны кабул итү (документларны тапшыру, аларның килү көнендә - 3 минут)

Гаризаны һәм документларны юллау

2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документларны тикшерү һәм эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәмен билгеләү турында яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү (документлар тапшырылган көнне - 3 минут)

Эшсез гражданинга кабул ителгән карарны җибәрү

Билгеләү турында карар

Билгеләүдән баш тарту турында карар

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәмен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү һәм имзалау (документлар килгән көнне - 3 минут)

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында боерык рәсмиләштерү һәм имзалау, эшсез гражданинга хәбәрләмә җибәрү (документлар килгән көнне - 3 минут)

| |
|---|
| Эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү (халыкның мәшгульлек үзәге счетына акча күчкән көнне - 5 минут) |

Регламентка 5 нче кушымтада карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында 20 ___ елның «__»_____________ № __________ карар»;

Регламентка 6 нчы кушымтада карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында 20 ___ елның «__»_____________ № __________ карар»;

Регламентка 7 нче кушымтада карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм башка җирлеккә күченеп урнашуда финанс ярдәме күрсәтү турында 20 ___ елның «__»____________ № __________ карар»;

Регламентка 11 нче кушымтада боерык исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа яшәү урынына күченеп урнашканда финанс ярдәмен билгеләү һәм аның күләме турында».